ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
АПАС ШӘҺӘР ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

КАРАРЫ

2025 ел, 17 февраль N 245

Апас шәһәр җирлеген төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Апас районы прокурорының 2025 елның 12 февралендәге протесты нигезендә, "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Апас шәһәр җирлеге Советы карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Апас шәһәр җирлеге Советының Апас шәһәр җирлеген төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында" 2017 елның 9 мартындагы 59 номерлы карары белән расланган Апас шәһәр җирлеген төзекләндерү кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) түбәндәге эчтәлекле 168.1 пункт өстәргә:

«168.1.Терлекләрне (йорт хайваннарын) йөртү Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы шәһәр тибындагы Апас поселогы Башкарма комитеты карары белән рөхсәт ителгән урыннарда башкарыла.»;

2) «Йорт хайваннарын һәм кошларын тоту» IX бүлеген үз көчен югалткан дип танырга.

2.Әлеге карарны "Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы" интернет - ресурсында бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (apastovo.tatarstan.ru).

3.Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.

4.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны җирлек башлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы "Апас шәһәр тибындагы поселогы" муниципаль берәмлеге башлыгы
Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Апас шәһәр җирлеге Советы Рәисе

А.Г. Җиһаншин